| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Борындык тимер юл станциясе поселогы

05.03.2025 № 1

**Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге башкарма комитетына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- ФАП территориясе;

мәктәп территориясе;

- балалар бакчасы территориясе;
- парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннары территориясе;
- балалар өчен уен мәйданчыклары территориясе.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы В.Г. Ранцева итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл
җирлеге башлыгы:



В.Г.Ранцев